РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

Буа шәһәре

КАРАР

31 март 2026 ел

№ 5-9

Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 19-24 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 19-24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 1.6 пунктта «күчемсез» сүзен төшереп калдырырга.

1.2. 7.2 пунктта беренче абзацта «дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең бәясен игълан итмичә» сүзләрен «минималь рөхсәт ителә торган бәя буенча» сүзләренә алмаштырырга, « шулай ук дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең минималь бәясе турында белешмәләрне үз эченә алырга» сүзләрен өстәргә;

икенче һәм өченче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

1.3. 4.15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, әлеге Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктының 1, 1.1, 5, 9 һәм 10 пунктчаларында каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлардан тыш, әлеге карарлар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта ачык файдалану мөмкинлегендә урнаштырылырга тиеш.»;

1.4. 4.16 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13) җиңүчеләрне (аукцион, махсуслаштырылган аукцион, конкурс уздырганда), йә сатып алучыларны (дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне рөхсәт ителә торган минималь бәядән сатканда), йә дәүләт яисә муниципаль мөлкәт сатып алу хокукына ия затларны (аны гавами тәкъдим ярдәмендә сатканда)билгеләү тәртибе;»;

1.5. 4.16 пунктка түбәндәге эчтәлекле 17 һәм 18 пунктчалар өстәргә:

«17) мондый мөлкәтне гавами сервитут һәм (яисә) әлеге Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда каралган чикләүләр белән йөкләүне билгеләү турында белешмәләр;

18) конкурс шартлары, аларны үтәү формалары һәм сроклары»;

1.6. 4.2 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) дәүләт мөлкәтен яисә муниципаль мөлкәтне минималь рөхсәт ителә торган бәядән сату;»;

1.7. 4.20 пунктның 7 абзацында «әлеге Федераль законның 24 статьясындагы 4 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне минималь бәядән сатуда бердәнбер катнашучы дип танылган зат» сүзләрен өстәргә.;

1.8. 5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «бу чакта дәүләт яисә муниципаль мөлкәт әлеге Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда һәм (яисә) гавами сервитутта каралган чикләүләр белән йөкләнергә мөмкин.»;

1.9. 5.3 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең бәясе турындагы тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан торглар үткәрү барышында ачыктан-ачык белдерелә. Сату нәтиҗәләре буенча аукцион җиңүчесе белән килешү төзелә.

Аукционда катнашуга гаризаны аукционда бердәнбер катнашучы дип танылган бер генә зат биргән очракта, мондый зат белән килешү дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуның башлангыч бәясеннән төзелә.

Аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат шартнамә төзүдән баш тарткан очракта, аукцион булмаган дип танылa.»;

1.10. 5.7 пунктның 5 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.11. 5.11 пунктта «аукцион җиңүчесе» сүзләреннән соң «йә әлеге статьяның 3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган зат» сүзләрен өстәргә.;

1.12. 5.12 пунктта «җиңүченең» сүзләреннән соң «йә әлеге статьяның 3 пунктының икенче абзацында билгеләнгән очракта аукционның бердәнбер катнашучысы дип танылган затның» сүзләрен өстәргә.;

1.13. Пункт 7.1:

беренче абзацта «бәясен игълан итмичә» сүзләрен «минималь рөхсәт ителә торган бәядән (алга таба - минималь рөхсәт ителә торган бәядән сату)» сүзләренә алмаштырырга»;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Минималь рөхсәт ителә торган бәядән сатканда дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең минималь бәясе, әгәр әлеге Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, гавами тәкъдим ярдәмендә сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән беренчел тәкъдим бәясенең 5 проценты күләмендә билгеләнә.";

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр гавами тәкъдим аша сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән беренчел тәкъдимнең бәясе 20 миллион сумнан артып китсә, минималь рөхсәт ителә торган бәядән сатканда дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең минималь бәясе беренчел тәкъдимнең мондый бәясеннән 10 процент күләмендә билгеләнә.»;

1.14. 7.1 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Минималь рөхсәт ителә торган бәядән сатканда дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең минималь бәясе, әгәр әлеге Федераль законда башкасы билгеләнмәгән булса, гавами тәкъдим ярдәмендә сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән беренчел тәкъдим бәясенең 5 проценты күләмендә билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр гавами тәкъдим аша сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән беренчел тәкъдимнең бәясе 20 миллион сумнан артып китсә, минималь рөхсәт ителә торган бәядән сатканда дәүләт яки муниципаль мөлкәтнең минималь бәясе беренчел тәкъдимнең шундый бәясеннән 10 процент күләмендә билгеләнә.»;

1.15. 7.3, 7.4 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Минималь рөхсәт ителгән бәядән сату катнашучылар составы буенча ачык.

4. Дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең бәясе турындагы тәкъдимнәр сатуда катнашучылар тарафыннан рөхсәт ителә торган минималь бәядән заявкалар кабул итү барышында ачыктан-ачык белдерелә. Минималь рөхсәт ителгән бәядән сату йомгаклары буенча сатып алучы белән дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе төзелә.

Сатуда катнашуга гаризаны минималь рөхсәт ителгән бәядән сатуда катнашуга кертелгән бер генә зат биргән очракта яисә гаризаларны һәм документларны карау нәтиҗәләре буенча бер генә зат минималь рөхсәт ителгән бәядән сатуда катнашырга рөхсәт ителгән очракта, күрсәтелгән зат минималь рөхсәт ителгән бәядән сатуда бердәнбер катнашучы дип танылa. Дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе мондый катнашучының дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең бәясе турындагы тәкъдиме бәясеннән рөхсәт ителә торган минималь бәядән сатуда бердәнбер катнашучы дип танылган зат белән төзелә.

5. Сатуда катнашуга гаризаларны минималь рөхсәт ителгән бәядән кабул итү вакыты кимендә илле көн булырга тиеш. Дәгъвачыларны минималь рөхсәт ителгән бәядән сатуда катнашучылар дип тану һәм аңа йомгаклар ясау күрсәтелгән заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

1.16. 8.1 пунктта «яисә башка федераль законнар, һәм гавами сервитут» сүзләрен (яисә) башка федераль законнар һәм (яисә) гавами сервитут сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Буа муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Ф.Еремеев